ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 37-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары М.М. Барыев һәм А.А. Чубаров тарафыннан кертелгән «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 37-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 23 декабре
№ 153-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
М.М. Барыев һәм
А.А. Чубаров тарафыннан
кертелде

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 бүлекнең исемендә «транспортта» сүзеннән соң «һәм автомобиль юлларыннан файдалану өлкәсендә» сүзләрен өстәргә;

2) 5.1, 5.2 статьяларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. статья. **Пассажир тарафыннан транспортта йөргән өчен, аның белән баручы балаларны йөрткән өчен түләүне раслау, шулай ук пассажир тарафыннан түләүсез яисә ташламалы йөрү хокукын раслау тәртибен бозу**

Пассажир транспортта йөргән өчен, аның белән баручы балаларны йөрткән өчен түләүне раслау, ул транспортта йөргән яисә балаларны йөрткән өчен түләргә тиеш булган очракларда, шулай ук пассажир Татарстан Республикасы чикләрендә билгеләнгән даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутлары буенча шәһәр, шәһәр яны юлларында һәм шәһәрара юлларда йөргәндә түләүсез яисә ташламалы йөрү хокукын раслау тәртибен бозган өчен –

ике мең биш йөз сум күләмендә административ штраф салына.^

5.2. статья. **Пассажир тарафыннан багаж ташыган, кул йөген йөрткән өчен түләүне раслау тәртибен бозу**

Пассажир Татарстан Республикасы чикләрендә билгеләнгән даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутлары буенча шәһәр, шәһәр яны юлларында һәм шәһәрара юлларда йөргәндә багаж ташыган, кул йөген йөрткән өчен түләүне раслау тәртибен бозган өчен –

бер мең сум күләмендә административ штраф салына.»;

3) 5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.9 статья өстәргә:

«5.9 статья. **Транспорт чарасы региональ һәм муниципальара әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юллары, региональ һәм муниципальара әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының түләүле участоклары буенча йөргән өчен түләүне кертү тәртибен үтәмәү**

1. Транспорт чарасы региональ һәм муниципальара әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юллары, региональ һәм муниципальара әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының түләүле участоклары буенча йөргән өчен түләүне кертү тәртибен үтәмәгән өчен, әлеге статьяның 2 өлешендә каралган очраклардан тыш, –

бер мең биш йөз сум күләмендә административ штраф салына;

2. Йөк транспорт чарасы яисә автобус региональ һәм муниципальара әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юллары, региональ һәм муниципальара әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының түләүле участоклары буенча йөргән өчен түләүне кертү тәртибен үтәмәгән өчен –

биш мең сум күләмендә административ штраф салына.

Искәрмәләр:

1. Әлеге статьяда каралган административ җаваплылыкка тартылган һәм, административ хокук бозу турындагы эш буенча карар чыгару көненнән алып егерме көннән дә соңга калмыйча, транспорт чарасы региональ һәм муниципальара әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юллары, региональ һәм муниципальара әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының түләүле участоклары буенча йөргән өчен түләүне кертү бурычын үтәгән зат административ җаваплылыктан азат ителә, ә әлеге административ хокук бозу хакындагы эш туктатылырга тиеш. Административ җаваплылыкка тартылган затка почта аша заказлы хат белән җибәрелгән административ җәза билгеләү турындагы карарның күчермәсе аның адресына мондый карарны чыгару көненнән соң егерме көн узганнан соң килгән очракта, күрсәтелгән срок Административ хокук бозулар

турында Россия Федерациясе кодексының 32.2 статьясындагы 1[3] өлешендә каралган тәртиптә торгызылырга тиеш.

2. Транспорт чарасы милекчесе (хуҗасы), әгәр әлеге статьяның 1 яисә 2 өлешендә каралган административ хокук бозу мондый хокук бозу беренче тапкыр фотога һәм киногә төшерү, видеога язу функцияләре булган автоматик режимда эшләүче махсус техник чаралар яисә фотога һәм киногә төшерү, видеога язу чаралары белән фиксацияләнгәннән соң һәр транспорт чарасына карата бер тәүлек эчендә ике һәм аннан артык мәртәбә фиксацияләнгән булса, мондый административ хокук бозу фиксацияләнгән тәүлек эчендә икенче һәм аннан соңгы очраклар өчен административ җаваплылыкка тартылмый.»;

4) 7.6 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.6 статья. **Транспорт комплексында, шул исәптән пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендә, дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы орган»;**

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Транспорт комплексында, шул исәптән пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендә, дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы орган әлеге Кодексның 5.1, 5.2, 5.6 (муниципальара пассажирлар йөртүгә карата) һәм 5.9 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карый.»;

5) 8.1 статьяның 14 өлешендә «5.2» саныннан соң «(тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль йөртүләргә карата)» сүзләрен өстәргә;

6) 8.3 статьяда «3.16, 3.17» саннарыннан соң «, 5.9» саннарын өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) Татарстан Республикасының транспорт инфраструктурасын үстерү, шулай ук пассажирлар йөртүне оештыру өлкәсендәге мәсьәләләрне алга таба регламентлаштыру максатларында әзерләнде.

1. 2024 елның 1 сентябреннән Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының түләүле автомобиль юллары, автомобиль юлларының түләүле участоклары буйлап транспорт чарасы йөргән өчен түләү кертү бурычын үтәмәгән өчен элек җаваплылык билгели торган $12.21^4$ статьясының гамәлдә булуы гомуми файдаланудагы федераль әһәмияттәге түләүле автомобиль юллары (аларның участоклары) буйлап транспорт чарасы йөргән өчен түләү кертү бурычын үтәмәгән очракларга гына кагыла.

Шул ук вакытта Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының күрсәтелгән статьясындагы искәрмәнең 3 пунктында Россия Федерациясе субъектларының гомуми файдаланудагы региональ һәм муниципальара әһәмияттәге түләүле автомобиль юллары, шулай ук аларның участоклары буйлап транспорт чарасы йөргән өчен түләү кертү тәртибен үтәмәгән өчен аларга карата административ җаваплылык билгеләү хокукы каралган.

Күрсәтелгән закон нигезләмәләре нигезендә Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 5 бүлегенә гомуми файдаланудагы региональ һәм муниципальара әһәмияттәге түләүле автомобиль юллары буйлап, шулай ук мондый юлларның түләүле участоклары буйлап транспорт чарасы йөргән өчен түләү тәртибен үтәмәгән өчен җаваплылык каралган норма өстәлә.

Закон проектында каралган штрафлар күләме Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләгән штрафлар күләме белән килештерелә һәм барлык транспорт чаралары өчен, йөк машиналарыннан һәм автобуслардан тыш, 1 500 сум тәшкил итә, ә алар өчен штраф 5 мең сум күләмендә билгеләнә.

Административ хокук бозуларны фиксацияләү фотога һәм кинога төшерү, видеога язу функцияләре булган автоматик режимда эшләүче махсус техник чаралар яисә фотога һәм кинога төшерү, видеога язу чаралары белән гамәлгә ашырылачак.

Административ хокук бозулар турындагы эшләр Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт комплексында дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы буларак Татарстан Республикасы Транспорт һәм юллар хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан каралачак.

2. 2021 елның 24 февралендәге 26-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» (алга таба – Устав) расланган 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы Федераль

законның 20 статьясына үзгәрешләр кертелде, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының түбәндәге тәртипләрне җайга сала торган норматив хокукый актлар кабул итү буенча вәкаләтләре билгеләнде:

- пассажир тарафыннан транспортта йөргән өчен, аның белән баручы балаларны йөрткән өчен түләүне раслау, ул транспортта йөргән яисә балаларны йөрткән өчен, шул исәптән Уставның 21 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән ташламалы түләү бирелеп, йөргән, багаж ташыган, кул йөген йөрткән өчен түләргә тиеш булган очракларда, шулай ук пассажир тарафыннан даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутлары буенча шәһәр, шәһәр яны юлларында һәм шәһәрара юлларда йөргәндә түләүсез яисә ташламалы йөрү хокукын раслау;

- Россия Федерациясе субъекты чикләрендә билгеләнгән даими рәвештә пассажирлар йөртү маршрутлары буенча шәһәр, шәһәр яны юлларында һәм шәһәрара юлларда йөргән, багаж ташыган һәм кул йөген йөрткән өчен түләүне раслауны тикшерү.

Бәян ителгәннәргә бәйле рәвештә Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 5.1 һәм 5.2 статьяларында каралган административ хокук бозулар составын төгәлләштерү таләп ителә.

Бер үк вакытта закон проектында тиешле хокук бозулар өчен административ штрафларның күләмнәрен үзгәртү карала.

Пассажир тарафыннан транспортта йөргән өчен, аның белән баручы балаларны йөрткән өчен түләүне раслау, шулай ук пассажир тарафыннан транспортта түләүсез яисә ташламалы йөрү хокукын раслау тәртибен бозган өчен штраф күләмен билгеләү шәһәр транспортында айлык юл йөрү билеты бәясенең зурлыгы нисбәтенә нигезләү тәкъдим ителә. Бүгенге көнгә күрсәтелгән бәя 1800 сумнан 2500 сумга кадәр тәшкил итә.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, закон проектында штраф күләмнәрен транспортта йөргән өчен түләүне расламаган өчен – 2 500 сум күләмендә, багаж ташыган һәм кул йөген йөрткән өчен түләмәгән өчен 1 000 сум күләмендә билгеләргә тәкъдим ителә.

Законны кабул итү административ җаваплылык билгеләү өлкәсендә хокукый җайга салуда төгәлсезлекләрне бетерергә мөмкинлек бирәчәк, шулай ук пассажирлар йөртүнең нәтиҗәлелеген арттыруга китерәчәк.

**Россия Федерациясенең башка субъектлары законнарына анализ**

| Россия Федерациясе субъекты | Транспортта йөргән өчен түләү тәртибен бозу | Багаж ташыган һәм кул йөген йөрткән өчен түләү тәртибен бозу | Акт реквизитлары |
|---|---|---|---|
| Тверь өлкәсе | 2 500 сум | 2 500 сум | 2022 елның 28 июлендәге 46-ЗО номерлы Тверь өлкәсе Законы |
| Чиләбе өлкәсе | 2 500 сум | 2 500 сум | 2023 елның 30 августындагы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | (кабат<br>5 000 сум) | | 893-ЗО номерлы<br>Чиләбе өлкәсе законы |
| Мәскәү | 2 000 сум | 1 000 сум | 2023 елның 31 маендагы<br>14 номерлы Мәскәү шәһәре законы |
| Курск өлкәсе | 1 500 сум | 500 - 1 000 сум | 2022 елның 20 декабрендәге<br>151-ЗКО номерлы<br>Курск өлкәсе Законы |
| Идел буе федераль округы | | | |
| Пермь крае | 2 500 сум<br>(кабат<br>5 000 сум) | 2 500 сум | 2023 елның 4 маендагы<br>175-ПК номерлы<br>Пермь крае Законы |
| Түбән Новгород | 1 000 сум | 500 сум | 2022 елның 2 декабрендәге<br>186-З номерлы<br>Түбән Новгород өлкәсе Законы |
| Ульяновск өлкәсе | 1 000 - 1 500 | 500 - 1 000 | 2022 елның 8 декабрендәге<br>127-ЗО номерлы<br>Ульяновск өлкәсе Законы |
| Марий-Эл Республикасы | 1 000 | 1 000 | 2023 елның 5 июлендәге<br>22-З номерлы<br>Марий Эл Республикасы Законы |
| Самара өлкәсе | 500 | 500 | 2012 елның 9 ноябрендәге<br>109-ДД номерлы<br>Самара өлкәсе законы |
| Саратов өлкәсе | 500 | 500 | 2023 елның 31 августындагы<br>98-ЗСО номерлы<br>Саратов өлкәсе законы |
| Чуваш Республикасы | 500 | 500 | 2022 елның 28 сентябрендәге<br>84 номерлы<br>Чуваш Республикасы Законы |
| Удмурт Республикасы | 500 | 500 | 2022 елның 16 ноябрендәге<br>57-РЗ номерлы<br>Удмурт Республикасы Законы |

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә кабул итүне таләп итми.

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.